КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 28 июнь г.Казань № 448

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларында квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2016 ел, 20 октябрь, 766 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларында квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2016 ел, 20 октябрь, 766 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«урта һөнәри белемнең төп һөнәри белем бирү программаларын – Татарстан Республикасының һөнәри белемнең тармак ресурс үзәкләре статусы булган һөнәри белем бирү оешмаларында хезмәт итүче квалификацияле эшчеләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар»;

әлеге карар белән расланган урта һөнәри белемнең төп һөнәри белем бирү программаларын – Татарстан Республикасының һөнәри белемнең тармак ресурс үзәкләре статусы булган һөнәри белем бирү оешмаларында хезмәт итүче квалификацияле эшчеләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә);

әлеге карарга, кушымта нигезендә, урта һөнәри белемнең төп һөнәри белем бирү программаларын – Татарстан Республикасының һөнәри белемнең тармак ресурс үзәкләре статусы булган һөнәри белем бирү оешмаларында хезмәт итүче

квалификацияле эшчеләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар өстәргә.

2. Бу карар Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмалары өлешендә 2017 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин